Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Бәтке поселогы **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«27» ноябрь, 2021 ел № 7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Бәтке» авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2022 елда яшәү урыны буенча Бәтке авыл җирлеге Бәтке поселогы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Бәтке авылы Үзәк ур. буенча тротуарны төзекләндерү эшләрен башкару;
- Бәтке авылында Төзүчеләр, Жемчужная, Северная, Үзәк урамнарында урам яктырткычларын сатып алып урнаштыру;
- Бәтке авылында Садовая, Набережная, Заречная, Ветвистая, Колхозная, Северная урамнарында юлларны ремонтлау;
- Бәтке авылы Колхоз урамындагы күперне ремонтлау;
- Бәтке авылы Гагарин ур., Үзәк ур., Новая ур. буенча күп фатирлы йортлар янындагы территорияне төзекләндерү (сатып алу, ташу, вак таш, асфальт валчыгы җәю);
- «Зеленый островок» паркы территориясен төзекләндерү (газонны кисү);

2. Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Бәтке поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Бәтке поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы В.А.Валиева